РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 27 » 02 2024 г. № 192

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге «Ситуацион үзәк төзү турында»гы 370 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 2 октябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында, Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарында, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарында эшләүче ситуацион үзәкләрнең функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру, норматив хокукый тәэминатына карата типлаштырылган таләпләр стандартын раслау, ситуацион үзәкләрнең функциональ, мәгълүмати-технологик, оештыру һәм норматив хокукый, Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган оешмалар һәм Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәгенә керә торган ситуацион үзәкләрне аккредитацияләү турында нигезләмәләр» турындагы 894 санлы карарын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасында бүленгән ситуацион үзәкләр челтәрен булдыру чараларын гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге «Ситуацион үзәк төзү

турында»гы 370 санлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының ситуацион үзәген төзү турында»;

1.2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының ситуацион үзәген (алга таба - ситуацион үзәк) булдырырга.»;

1.3. Карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының ситуацион үзәге турында нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ситуацион үзәге эшчәнлеге турында хисап формасын (2 нче кушымта).»;

1.4. Карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарын ситуацион үзәкнең җитәкчесе итеп билгеләргә.»;

1.5. Карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ситуацион үзәген (алга таба - Җаваплылык үзәге) булдыру һәм эшләве өчен җаваплылык үзәге итеп Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеген билгеләргә, аңа Ситуация үзәге администраторы вәкаләтләрен бирергә.»;

1.6. Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җаваплылык үзәгенә:

мәгълүмат ресурслары һәм мәгълүмати-аналитик модельләр паспортларын эшләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә аларны Татарстан Республикасы Бүленгән ситуация үзәгенең мәгълүмати ресурслар һәм мәгълүмати-аналитик модельләр реестрына кертү;

ситуацион үзәктә мәгълүмати ресурсларны һәм мәгълүмати-аналитик модельләрне формалаштыру һәм актуальләштерү регламентын эшләү һәм раслау өчен кертү;

эштә кулланыла торган мәгълүмат ресурсларын ситуацион үзәкнең мәгълүмат базасына кертергә һәм аларны актуальләштерүне тәэмин итәргә, мәгълүмати-аналитик модельләрнең эшләве өчен кирәкле башлангыч мәгълүматны актуальләштерүне тәэмин итәргә;

паспортларында күрсәтелгән модельләрнең актуальләшү чорына ярашлы рәвештә мәгълүмати-аналитик модельләрне актуаль хәлдә тотуны тәэмин итәргә.»;

1.7. Карарны түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга:

«6. Таблицага ярашлы рәвештә Мәгълүмати-аналитик модельләрне җаваплылык Үзәгенә беркетергә:

| Мәгълүмати-аналитик модель исеме | Хисап бирү ешлыгы |
| --- | --- |
| Тулаем территориаль продуктка кече эшмәкәрлек субъектларының йогынтысын бәяләү | еллык |
| Хезмәт хакын минималь хезмәт хакына җиткерүнең йогынтысын бәяләү | квартал |
| Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы бюджеты дефицитын компенсацияләүгә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативын фаразлау | еллык |
| Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының хуҗалык итүче кече бизнес субъектларын чагыштырма анализлау | квартал |

»;

1.8. Карарның 5 пунктын 7 пункт дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге «Ситуацион үзәк төзү турында»гы 370 санлы карарының 1 нче кушымтасына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2.1. Карарның 1 нче кушымтасының атамасын түбәндәге эчтәлектәге атама белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының ситуацион үзәге турында нигезләмә»;

2.2. Карарның 1 нче кушымтасының 1 нче пунктындагы 1.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ситуацион үзәгенең бурычларын, функцияләрен һәм эш тәртибен билгели.»;

2.3. Карарның 1 нче кушымтасының 1 нче пунктындагы 1.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге 1 абзац белән тулыландырылырга:

«мәгълүмат ресурсы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының һәм Татарстан Республикасы Бүленгән ситуацион үзәгенең мәгълүмат системалары составына керә торган хуҗалык субъектларының мәгълүматы;»;

2.4. Карарның 1 нче кушымтасының 2 нче пунктындагы 2.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хакимият органнары, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аппаратлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты сораулары буенча мәгълүмати, мәгълүмати-белешмә һәм мәгълүмати-аналитик материаллар әзерләү.»;

2.5. Карарның 1 нче кушымтасының 4 нче пунктындагы 4.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Ситуацион үзәкнең администраторы булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге тора.».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 10 июнендәге «Ситуацион үзәк төзү турында»гы 370 санлы карарының (алга таба - Карар) 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

3.1. Карарның 2 нче кушымтасының атамасын түбәндәге эчтәлектәге атама белән тулыландырырга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы ситуацион үзәге эшчәнлеге турында хисап»;

3.2. «1 бүлек. Текст форматындагы гомуми мәгълүмат» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина